КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 июнь г.Казань № 400

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

34 таблицадан соң икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт социаль яклау учреждениесе һәм «Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе җитәкчеләренә хезмәткә түләү буенча 1 төркем билгеләнә.»;

Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 8 пунктында «Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә мәгълүмати-методик үзәк» сүзләрен «Республика ресурс үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларына һәм эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 8 пунктында «Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә мәгълүмати-методик үзәк» сүзләрен «Республика ресурс үзәге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар «Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесен дәүләт теркәвенә алган мизгелдән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\400.docx